Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге

Питрәч авыл җирлеге башлыгы
# КАРАРЫ

14 февраль, 2025 ел № 1

Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч ав., Казан ур., адресы буенча кадастр номеры 16:33:120107:1114 булган җир кишәрлегендә гыйбадәтханә төзү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Питрәч авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2017 елның 18 августындагы 65 номерлы карары (2017 елның 15 декабрендәге 79 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 92 номерлы, 2019 елның 08 октябрендәге 137 номерлы, 2022 елның 16 мартындагы 60 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 69 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч ав., Казан ур., адресы буенча кадастр номеры 16:33:120107:1114 булган җир кишәрлегендә гыйбадәтханә төзү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар үткәрергә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. иҗтимагый фикер алышулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты;

2.2. Үткәрү датасы һәм вакыты - 2025 елның 28 феврале 16:00 сәгатьтә;

2.3. Үткәрү урыны - “КиноКадр” кинотеатры, РТ, Питрәч районы, Питрәч ав., Совет ур., 7 й. адресы буенча.

2.4. фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне тәбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Совет урамы, 18 йорт, e-mail: pes.pes@tatar.ru җибәрергә;

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитетына:

3.1. Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч ав., Казан ур., адресы буенча кадастр номеры 16:33:120107:1114 булган җир кишәрлегендә гыйбадәтханә

төзү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар үткәрергә

3.2.Җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләрен «Вперед» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми (www.pestreci.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга;

3.3. «Вперед» («Алга») газетасында иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында хәбәрне бастырырга.

4. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Сөләйманов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ